# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Бикбау торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында

№1 20 ноябрь 2023 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ атарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 20 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2024 елда Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Бикбау торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасында укучы студентлар, Россия армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Бикбау торак пунктында су манарасын сатып алу һәм урнаштыру (материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);
2) Бикбау торак пунктында юл кырыен һәм аның тирәсендәге территорияне үләнне чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә җыенда катнашучы 326 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 168 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен җыенда катнашкан 157 кеше тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 11 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Бикбау торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип игълан итергә. Сорау буенча карар кабул ителде дип танырга:

«2024 елда Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Бикбау торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы

гаиләләрдән, көндезге уку формасында укучы студентлар, Россия армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Бикбау торак пунктында су манарасын сатып алу һәм урнаштыру (материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);
2) Бикбау торак пунктында юл кырыен һәм аның тирәсендәге территорияне үләнне чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү)
кабул ителгән.

2. Гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Бикбау авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә. http://menzelinsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Бикбау авыл җирлеге составына керүче Бикбау торак пунктында гражданнар җыенының әлеге карарын Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: ____________ Л. Н. Мәрдәмшина

Бикбау авыл җирлеге башлыгы: ____________ Л. Н. Мәрдәмшина